Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге составына керүче
Олы Елга һәм Сабакай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

**2022 елның 3 августы** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 3 августында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге сораулар белән беркетмә төзелде:

"Гражданнар җыены 30.11.20021 ел, № 1 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә килешәсезме?:

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган үзара салым акчалары җибәрелә торган эш төрләре исемлегенә түбәндәге пунктларны кертергә:

- Олы Елга авылында зиратка илтүче юлларны төзекләндерү (вак таш сатып алу, вак таш ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү, вак таш җәю, эш өчен түләү;

- Казаклар авылы балалар мәйданчыгы территориясен койма (киртә, рәшәткә) белән әйләндереп алу (материал сатып алу, шартнамә нигезендә эшләр өчен түләү);

- елның салкын вакытында җир эшләре өчен таш ваткыч чүкеч (отбойный молоток) һәм кискеч сатып алу.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 708 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 424 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 424 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Олы Елга һәм Сабакай авылында

гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип **расларга**: "Гражданнар җыены 30.11.20021 ел, № 1 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә килешәсезме?:

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган үзара салым акчалары җибәрелә торган эш төрләре исемлегенә түбәндәге пунктларны кертергә:

- Олы Елга авылында зиратка илтүче юлларны төзекләндерү (вак таш сатып алу, вак таш ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү, вак таш җәю, эш өчен түләү;

- Казаклар авылы балалар мәйданчыгы территориясен койма (киртә, рәшәткә) белән әйләндереп алу (материал сатып алу, шартнамә нигезендә эшләр өчен түләү);

- елның салкын вакытында җир эшләре өчен таш ваткыч чүкеч (отбойный молоток) һәм кискеч сатып алу**.**

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорты; Сабакай авылы, Үзәк урамы, 9 йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Олы Елга, Сабакай торак пунктларында гражданнар җыены Карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ф.А.Садриев

Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Садриев